«Рассмотрено»
Руководитель МО

Хузина Ф.Т.
Протокол № 1
от «23» 08 2017 г.

«Согласовано»
Заместитель директора по УРВ ЧОУ «Академический Лицей им. Н.И. Лобачевского»
_________ Яковлева М.В.

от «23» 08 2017 г.

«Утверждаю»
Директор
ЧОУ «Академический Лицей им. Н.И. Лобачевского»
_________ Беспалова Т.В.
Приказ № 43
от « 25» 08 2017 г.

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

учебного предмета, курса, дисциплины (модуля)
ЧОУ «Академический Лицей им. Н.И. Лобачевского»

Гайнуллина Гульназ Фаатовна, к.п.н.
Ф.И.О., категория

по татарской литературе, 8А класс
предмет, класс и т.п.

Рассмотрено на заседании
педагогического совета
протокол № 1
от «23» 08 2013 г.

20 17 - 20 18 учебный год

# УЧЕБНО-ТЕМАТИЧЕСКОЕ ПЛАНИРОВАНИЕ ПРАКТИЧЕСКОЙ ЧАСТИ УЧЕБНОЙ ПРОГРАММЫ ПО ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЕ

Класс: 8А

Учитель: Гайнуллина Г.Ф.

Количество часов: всего - 70;  в неделю – 2.

Плановых контрольных работ: 4

Административных контрольных работ: 2

**8 сыйныф өчен татар әдәбиятыннан эш программасы**
**Укытучы: доцент Г.Ф.Гайнуллина**

**Эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелде:**

1. “Россия Федерациясендә мәгариф турында”гы Федераль законы (Федеральный законот 29.12.2012. № 273 – ФЗ «Об образовании в Российской Федерации»).

2. “Мәгариф турында” Татарстан Республикасының Законы.(Закон Республики Татарстан “Об образовании” №68 от 22.07.2013)

3. ”Россия Федерациясе халыкларының телләре турында” 126 нчы номерлы Федераль закон” (24.07.1998)

4. “2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү” Дәүләт программасы” (ТР МК №794 25.10.2013).

5. Төп гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандартының региональ компоненты (Россия Мәгариф һәм Фән министрлыгында 2010 нчы елның 17 нче декабрь боерыгы 1897 нче номер белән расланган,РФ Юстиция Министрлыгында 19644 нче регистрацион номеры белән 2011 нче елның 1 нче февралендә теркәлгән).

6. Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен укыту программасы(рус телендә сөйләшүче балалар өчен) 1-11 нче сыйныфлар.Төзүче-авторы: К.С.Фәтхуллова. Казан, 2014.

7. Казан шәһәре Н.И.Лобачевский исемендәге академик лицейның педагогик коллективының 2017 нчы елның 28 августындагы 1 нче номерлы педсовет карары буенча 2017/18 нче уку елына кабул ителгән укыту планы.

8. Казан шәһәре Н.И.Лобачевский исемендәге академик лицейның белем бирү программасы.

9. Дәреслек: Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен). 8 сыйныф. Ике кисәктә. / Ә.Р.Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанов, Э.Х. Гыйззәтуллина; [рәссамы Диләрә Нәүрүзова]. –Казан: “Мәгариф –Вакыт” нәшр., 2014.

## Аңлатма язуы

**Рус телендә сөйләшүче балаларга татар әдәбияты укытуның төп максаты:**

– туган халкының һәм җирле халыкның телен, мәдәниятен, әдәбиятын яхшы белгән, һәрьяктан камил, милли горурлык хисләре үскән шәхес тәрбияләү;

– татар сөйләмен тыңлап аңларга күнектерү, текстларны аңлап уку күнекмәләрен үстерү;

– татар телендәге сөйләмне фонетик, лексик, грамматик яктан дөрес төзергә күнектерү;

– татар халкының фән, мәгариф, сәнгать, мәдәният өлкәсендәге казанышлары, күренекле шәхесләре белән таныштыруны дәвам итү;

– халыкларның үзара аңлашып, тату яшәвенә омтылыш тәрбияләү;

– укучыларны татар телен өйрәнүгә ихтыяҗын арттыру.

**Рус телендә сөйләшүче балаларга татар әдәбияты укытуның бурычлары:**

– Татарстан төбәгендә яшәп, җирле халык белән аралашкан укучыларны төбәкнең әдәби-мәдәни байлыгы белән якыннан таныштыру;

– татар әдәбияты турында мәгълүматларны төрле халык фольклоры, әдәбияте, мәдәнияте, милли образлары белән чагыштырма-топологик аспектта бирү;

– татар халык авыз иҗаты турында тулы күзаллау булдыру, аны баланың туган халкының рухи җәүһәрләре белән чагыштырырга күнектерү;

– татар әдипләре, сәнгать әһелләре турында күзаллау булдыру, аларны танырга, иҗатларын аңларга, башка халыкларның сүз сәнгатен, культурасын үстерүчеләр белән чагыштырма планда бәяләргә өйрәтү;

– татар, рус, Россиядә яшәүче башка халыклар, бөтендөнья әдәбияты белеме казанышларының уртак нигезен аңлау, аларны үстерү һәм киңәйтү

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

1) әдәби әсәрләрне сүзләрен дөрес әйтеп, йөгерек уку;

2) авторның әйтергә теләгән фикерен аңлау, үз мөнәсәбәтен белдерү, әсәрне өлешләргә бүлә һәм планын төзи белү;

3) әдәби-теоретик төшенчәләрне рус әдәбияты белеме белән тәңгәлләштерү;

4) татар әдәбиятының һәм тарихи мәгълүматларның дөнья культурасында тоткан урынын аңлау;

5) авторның тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача күзаллау;

6) 11-12 татар, рус, чит ил язучы-шагыйрьләренең исемнәрен һәм алар язган әсәрләрне белү;

7) 5-6 сәнгать әһеленең тормышы, иҗаты турында мәгълүматлы булу;

8) Казан һәм Татарстан төбәгендә мәдәният учаклары, балалар матбугаты турында белү;

9) төрле халыкларның фольклор үрнәкләрен татар халык авыз иҗаты белән чагыштыру;

10) 7 мәкаль, 7 әйтемне русча эквивалентлары белән истә калдыру;

11) төрле авторларның 3-4 шигырен яттан сөйли белү;

12) сүзлекләр, энциклопедияләр, Интернет-ресурслардан файдаланып, үзенә кирәкле материалны табу;

14) әдәби әсәрне тормыш белән бәйләп, үз гамәлләренә бәя бирү.

**Курс эчтәлеге**

**I. Тарих китабында безнең өчен бик күп хатирәләр саклана**

Халык авыз иҗаты. Фольклор жанрлары буларак риваятьләр, аның ничек барлыкка килүе.Риваять төрләре.

Тарихи риваятьләр. Татар халыкының “Сихерче кыз” риваяте. Әсәрдә Казан образының бирелеше, тарихы. Әлеге риваятькә хас әкияти алымнар.
Топонимик риваятьләр. Татар халкының “Гали тугае” риваяте. Урта гасыр Европа халкының “Моргана”риваяте. Шәһәр, авыл, тау һәм елга атамаларының килеп чыгышы .

Легендалар. Аның төрләре. Легенданың риваятьтән аермалы яклары.
Татар халкының «Зөһрә кыз» легендасы. Легендада Зөһрә образының бирелеше. Әсәрдә хыял мотивлары, аның кеше язмышын ачудагы роле. Әсәрдә гаиләдәге мөнәсәбәтләрнең бирелеше.

Музыка уен кораллары, аларның халык тормышындагы роле .

**II. Без тарихта эзлебез**.

Тарихи ядкарьләр буларак сәяхәтнамә һәм елъязма жанрлары. Ибне Фадлан – X гасырның беренче яртысында яшәгән гарәп сәяхәтчесе. Ибн Фадланның 921 – 922 нче елларда Болгар дәүләтенә сәфәре вакытында язылган сәяхәтнамәсе. Болгар дәүләтенең ил тарихындагы роле. Ил башлыгы Алмыш.

Фатих Кәрими. Әдип һәм журналист тормышы һәм иҗат юлы. Аның Европа илләренә сәяхәте, бу сәяхәтнең максаты. «Аурупа сәяхәтнамәсе» әсәреннән өзек. Европа илләрендәге культура учаклары, Петербург китапханәсе турында мәгълүмат. «Аурупа сәяхәтнамәсе»нең әдәби роле.

Миргазиян Юныс. Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Татар әдәбиятында диңгезчелек (маринистика) жанрына нигез салуы. Язучының “Су” хикәясе.

Әдәбият теориясе. Тарихи роман турында төшенчә .Тарихи һәйкәл буларак Казан Кремле, аның төзелү тарихы. Кремльнең бүгенге торышы.
Габдулла Тукай. Язучының 1895 нче елда Җаек (Уральск) шәһәренә китүе. Анда Тукайның җәмәгать эшлеклесе, журналист, тәрҗемәче һәм шагыйрь буларак формалашуы. 1907 нче елда кире Казанга кайтуы. Шагыйрь иҗатының Казан чоры. Казанда аралашкан дуслары, балалар әдәбиятына һәм халык әдәбиятын өйрәнүгә керткән өлеше, театр эшчәнлегенә игътибары, сәяхәтләре, иҗтимагый эшчәнлеге. “Әл-ислах” газетасындагы эшчәнлеге. Габдулла Тукайның “Пар ат” шигыре. Аның язылу тарихы. “Пар ат” шигыренең лирик герое, аның кичерешләре, өметләре. Пар ат образының символикасы. Табигать, кучер образларының бирелеше, мәгънәләре .

Бакый Урманченың “Пар ат” шигыренә иллюстрациясе. Картинада Габдулла Тукай шигырендә сурәтләнгән вакыйганың бирелеше.
Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе. Премиянең беренче лауреатлары.

Күренекле рәссам, сынчы Бакый Урманченың (1897 – 1990) тормышы. Ул тудырган скульптур портретлар, картиналар .

Наҗар Нәҗми. Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы. Аның Тукай шәкерте булуы, аның идеяләрен үстерүе. Н.Нәҗми иҗат иткән әсәрләрдә Тукай образының бирелеше, мәгънәсе. Шагыйрьнең «Татар теле» әсәрендә Тукай традицияләрен дәвам итүе. Н.Нәҗминең Бөек Болгарга сәфәре турындагы “Агыйделдә ак пароход” әсәреннән өзек. Әсәрдә сурәтләнгән “түгәрәк өстәл”, анда катнашкан язучылар. Әсәрнең әдәби мәгънәсе, кыйммәте.

## III. Онытылмас еллар

Гариф Ахунов. “Замандашлар портреты” әсәреннән өзек. Язучының әсәрдә рәссам Виктор Куделькинның иҗатын яктыртуы, аның картиналары турында уйланулары. Рәссам иҗатында М.Җәлил образы, аның бирелеше, иҗатчының халык язмышының кискен дәверләрен полотнода сурәтләве. В.Куделькинның “Билгесез биеклектә” картинасы, Бөек Ватан сугышы.

Сугыш турындагы җырлар. Роберт Әхмәтҗановның “Озатып вокзаллар каршында…” (“Солдатлар”) шигыре. Сугышка баласын озаткан Ана образы. Татар халкының “Герман көе” җыры. Музыка сәнгатенең матур әдәбият белән тыгыз бәйләнештә булуы һәм бер-берсенә йогынтысы.

Фатих Кәримнең тормышы, иҗаты. Аның иҗатында сугыш темасы, образларның бирелеше. Шагыйрьнең “Ант” шигыре, «азатлык» һәм «явызлык» проблемалары. “Кыңгыраулы яшел гармун” поэмасы, андагы образлар системасы. Гармун һәм җыр образының роле. Әлеге лирик әсәрләрдә сугыш проблемасының бирелеше.

Туфан Миңнуллин. Күренекле драматург, язучы, публицист һәм җәмәгать эшлеклесенең тормышы һәм иҗаты. “Моңлы бер җыр” драмасы. Әсәрдә М.Җәлил образының бирелеше, аның тоткынлыктагы тормышы. Драмада фәлсәфи мотивлар, фантастик алымнарның роле.

Т.Миңнуллинның “Моңлы бер җыр” публицистик драмасы турында белешмә.

Казанда Муса Җәлил һәйкәле һәм җәлилчеләргә куелган барельефлар.
Марсель Сәлимҗанов. Режиссёрның тормышы, иҗаты. Аның татар профессиональ театрының, милли драматургиянең үсешенә керткән өлеше.
Ринат Таҗетдинов. Халык артистының тормышы һәм иҗаты, ул тудырган онытылмас образлар.

Фронт хатлары, аның халык тормышындагы роле. Муса Җәлилнең кызы Чулпанга язган хаты, Фәтих Кәрим хатлары. Татар әдәбиятында эпистоляр жанр.

Әдәбият теориясе. Эпистоляр жанр турында төшенчә .

Мостай Кәрим. Шагыйрь һәм язучының тормышы, иҗаты. “Билгесез солдат” шигыре. Шигырьдәбилгесез солдат образы. Лирик геройның кичереше, шәхесләр язмышы .ЧыңгызАйтматов. Әдип турында белешмә. Аның “Анам кыры” әсәре. Әсәрдә Тулганай, Җир-ана образлары. Җыелма Җир-ана образына салынган мәгънә. Авторның сугыш турындагы уйланулары. «Анам кыры» повесте турында белешмә.

**IV. Әтинең зур бүреге иртә киелде.**

Клара Булатова. Шагыйрә турында белешмә. “Башым иям” шигыре, сугыш афәтенең шагыйрәнең балачагына тәэсире, хатирәләрендә калдырган .
Нур Әхмәдиев. Язучы иҗаты турында белешмә. “Җиңү көне” шигыре. “Минем туган көнем” хикәясе.

Разил Вәлиев. Тормышы һәм иҗади эшчәнлеге. “Ватаным” шигыре. Сугыш, аның гади халык, балалар җилкәсенә алып килгән авырлыгы.

**V. Ана — изге, Ана — бөек, аңа — дан!**

Аңлар өчен йөрәгенең олылыгын,
Туу кирәк кайчак безгә яңадан!

Шәриф Камал. Әдипнең тормышы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат. “Буранда” новелласы. Төп геройның язмышы. Аның эчке дөньясы, күңел халәте. Психологик алымнар. Әсәрдә Ана образына хас сыйфатлар.

Әдәбият теориясе. Әдәби деталь. Матур әдәбиятта психологизм. Новелла турында төшенчә.

Ибраһим Салахов. Язучының тормышы һәм иҗаты. Репрессияләнгән әдипләр язмышы. “Халык дошманы” төшенчәсе. “Ана тавышы” хикәясе (“Колыма хикәяләре” циклыннан). Ялгыз ананың аяныч язмышы, кичерешләре. Автор әйтергә теләгән фикер.

Сибгат Хәким. Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты турында мәгълүмат. Иҗатында яктырткан темалар. “Әнкәй” шигырендә Ана образына хас сыйфатлар. Лирик геройның хис-кичерешләр бирелеше. Сагыну хисе. “Җырларымда телим” шигыре. Шигырьнең эчтәлеге, поэтик яңгырашы, сурәтләү чаралары. Шигырьдә күтәрелгән проблемалар.

Роберт Миңнуллин. Әдипнең тормыш юлы, иҗаты. Әдәбиятка булган мәхәббәте. Иҗатында яктыртылган темалар. “Әнкәй” шигыре. Ана образының бирелеше. Лирик геройның уйлары, кичерешләре.

Марсель Галиев. Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты турында мәгълүмат. “Су буеннан әнкәй кайтып килә” шигыре. Шигырьдә ана образы. Лирик геройның туган ягы турында хис-кичерешләре. “Кабатланмас әкият” шигыре. Хыялда туган авыл күренеше. Балачакка кайту теләге, лирик геройның хис-кичерешләре. Ана образының бирелеше Луиза Батыр-Болгари. Композиторның тормыш юлы, иҗаты.

Шәриф Хөсәенов. Әдипнең тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат. Беренче драмалары турында белешмә. “Әниемнең ак күлмәге” (“Әни килде”) драмасы. Драмада ана образының бирелеше. Ананың язмышы, балаларына булган мәхәббәте. Автор әйтергә теләгән фикер. Шәриф Хөсәеновның “Әниемнең ак күлмәге” (“Әни килде”) драмасы турында. Драманың татар әдәбиятында тоткан урыны. Ана образы турында мәгълүмат. Аналар һәм балалар проблемасы.

Фоат Садриев. Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Таң җиле” романы. Романда бирелгән образларның язмышы, ана (Нуриәсма) образының бирелеше. Нәсимә белән Фәритнең үз-үзләрен тотышы, уллары Маратның авылда терелүе, сөйләшә башлавы, дуслар табуы. Авторның әйтергә теләгән фикере.

**VI. Көлсәң – көл, еласаң – ела!**

Беренче сатирик журналлар. Беренче сатирик журналлар турында белешмә. Вакытлы матбугатны башлап җибәргән шәхесләр.

Әдәбият теориясе. Сатира турында төшенчә.

Галиәсгар Камал. Әдипнең тормыш юлы, иҗаты, татар әдәбиятында тоткан урыны. “Банкрот” сатирик комедиясе. Сираҗетдин Туктагаевның тормыш, көнкүреше, уйлаган хәйләсе. Тирә-юньдәге образларның үз-үзләрен тотышы. Галиәсгар Камалның “Банкрот” комедиясе турында белешмә. Әсәрнең сәхнә тарихы. Әдип тарафыннан күтәрелгән проблема.

Әдәбият теориясе. Конфликт турында төшенчә. Сарказм. Проза әсәрләрендә сатира.

Гамил Афзал. Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат. Юмор-сатира өлкәсендә тоткан урыны “Юл газабы” хикәясе. Хикәяләүче авторның язмышы турында белешмә.“Тәвәккәләби” шигыре. Әбинең аянычлы язмышы, эш-гамәлләре.  Шигырьнең эчтәлеге, поэтик яңгырашы.Автор идеясе. Сурәтләү чаралары. Шигырьдә күтәрелгән проблемалар.

Әдәбият теориясе. Сатирик шигырь. Ирония турында төшенчә .

Зәки Нури. “Пародия”. Пародиянең язылу стиле. Пародиягә салынган эчтәлек. Төрле шәхесләргә багышланган эпиграммалар. Эпиграммаларда сарказм.

Әдәбият теориясе. Пародия турында төшенчә. Эпиграмма .

**VII. Даһи гомере – халкы хәтерендә!**

Ренат Харис. Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Гармунчы” поэмасы.Поэманың эчтәлеге. Лирик геройның бирелеше. Поэмада кулланылган сурәтләү чаралары.Гармуннан чыккан көйләрнең сурәтләнеше. “Ике гөл” шигыре. Шигырьнең идеясе, төзелеше. Шигырьгә салынган мәгънә. Автор әйтергә теләгән фикер.

Зөлфәт. Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Юмор-сатира өлкәсендә  ирешкән уңышлары. “Шигырем – ачык!” ,“Шундый чагы әле җанымның” шигырьләре. Аларда лирик геройның хис-кичерешләре. Әдип шигыренә хас үзенчәлекләр.

Әдәбият теориясе. Документаль повесть жанры .

Рабит Батулла. Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Төрле жанрларда иҗат итүе. “Бию” кыйссасы. Рудик белән бәйле, госпитальдә булган көлкеле вакыйганың әдәби гәүдәләнеше. Яшь талантның беренче уңышы.

**VIII. Табигатьнең дә җаны бар.**

Айдар Хәлим.  Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Өч аяклы ат” повесте. Әсәрнең эчтәлеге. Кәбирнең язмышы, атка мөнәсәбәте.

Анық тирәсендә булган башка геройларның үз-үзләрен тотышы. Ат образының бирелеше .

Гарәфи Хәсәнов. Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Беренче күк күкрәү” хикәясе.Язгы табигать күренешенең сурәтләнеше. Геройның язгы табигать турында уйлары, хис-кичерешләре. Беренче күк күкрәү мизгелләренең тасвирланышы .

Камил Кәримов. Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Тимергали бабай хикәяте” хикәясе. Хикәянең эчтәлеге. Авторның Сабантуй бәйрәмен тасвирлау үзенчәлеге. Заманга хас булган атрибутларның бирелеше (кулъяулык бирү, аулак өй күренеше һ.б.) .

“Ялкын” журналы. Журналның тарихы. Журнал рубрикалары. Мәкаләләрнең эчтәлеге.

**Ятлау өчен тәкъдим ителә торган әсәрләр**

Г.Тукайның “Пар ат” шигыреннән өзек.

Ф.Кәримнең “Ант” шигыре

Р.Вәлиевнең “Ватаным” шигыре.

С.Хәкимнең “Җырларымда телим” шигыре.

Р.Харисның “Ике гөл” шигыре.

**2017 – 2018 нче уку елы**
**Татар әдәбиятыннан тематик планлаштыру**

Класс: 8
Укытучы: Гайнуллина Г.Ф.
Сәгать саны : барлыгы 35, атнага 1
Планлаштырылган контроль дәресләр: 3

| № | Укыту фәненең бүлекләре | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Тарих китабында безнең өчен бик күп хатирәләр саклана. | 3 |
| 2 | Без тарихта эзлебез. | 4 |
| 3 | Онытылмас еллар. | 7 |
| 4 | Әтинең зур бүреге иртә киелде. | 3 |
| 5 | Ана — изге, Ана — бөек, аңа — дан! | 6 |
| 6 | Көлсәң – көл, еласаң – ела! | 3 |
| 7 | Даһи гомере – халкы хәтерендә! | 2 |
| 8 | Табигатьнең дә җаны бар. | 7 |
| **Барлыгы:** | | 35 |

## Календарь-тематик план

| № | Дәрес темасы | Укучылар эшчәнлегенә характеристика |
|---|---|---|
| 1 | **Тарих китабында безнең өчен бик күп хатирәләр саклана ( 3сәг)** Ачыла тарихның пәрдәсе. Фольклор. Риваятьләр. | Дәреслектә биремнәр, риваять б-н әкиятнең уртак якларын табу, нәтиҗәләр чыгару.. Риваять жанры турында теоретик төшенчә бирү, халкыбыз тарихы б-н бәйләү. Фольклор турында белемнәрне гомумиләштерү, риваять турында белешмә бирү, “Сихерче кыз” риваяте б-н танышу. |
| 2 | Сезгә – ялган, миңа- чын. Легендалар | Әсәрне уку, сорауларга җавап бирү,легенда б-н риваятьләр арасында аермалы якларны билгеләү. Фольклор жанрлары б-н танышуны дәвам итү, легенда жанрын өйрәнү, ”Зөһрә кыз” легендасын уку. |
| 3 | “Халыкныкы халыкта саклана” | Халкыбыз тарихы турында белем бирү, шәһәр, елга, авыл исемнәренең килеп чыгышын аңлату. Фольклор жанрлары турында белемнәрен ныгыту. Укучыларда татар халкының үткәненә, атамаларның килеп чыгышына кызыксыну тәрбияләү, дөрес бәяләү күнекмәләре булдыру |
| 4 | **Без тарихта эзлебез (4сәг)** Тарих- тормыш остазы. Сәяхәтнәмә | Өзекне уку, тәрҗемә итү, диалог төзү, сорауларга җавап бирү, сүзлек белән эш. Болгар дәүләтенең ил тарихындагы ролен ачыклау,сәяхәтнәмә жанры турыда күзаллау булдыру. Ибне Фадлан турында белешмә бирү, 921-922 елларда Болгар дәүләтенә сәфәре вакытында язылган сәяхәтнәмәсен өйрәнү. |
| 5 | Энҗе табучы әдип. М.Юныс иҗаты | Фронталь әңгәмә, язучы турында презентация карау,сәнгатьле уку,сорауларга җавап бирү,анализ, тәрҗемә, сүзлек белән эш. Язучы яшәгән чорга бәя бирү, тарихны аңлау. М.Юныйсның тормыш юлы һәм иҗатын,”Су” хикәясен өйрәнү. |
| 6 | Җиктереп пар ат, Казанга! Г.Тукай иҗаты | Видеоязма карау, шигырьне язмада тыңлау,сәнгатьле уку, сорауларга җавап бирү,фикер алышу, тәрҗемә, сүзлек белән эш . Тукайның тормышы һәм иҗаты турында өстәмә |

| | | |
|---|---|---|
| | | мәгълүмат бирү, “Пар ат” шигырен уку. |
| 7 | Нажар Нәҗми – Тукай шәкерте | Һәр абзацны уку,эчтәлекне аңлаганны  тикшерү өчен,гади сораулар бирү,сүзлек өстендә эш,тәрҗемә эше. Н.Нәҗми тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, ”Агыйделдә ак пароход” әсәрен өйрәнү. |
| 8 | **Онытылмас еллар (7сәг)** Тырышса да дошман шагыйрьләрне аера алмый җырдан, халыктан | Сәнгатьле уку,җырларны тыңлау һәм өйрәнү, сорауларга җавап бирү,фикер алышу, тәрҗемә, сүзлек белән эш. Музыка сәнгатенең матур әдәбият белән тыгыз бәйләнештә булуын күзәтү. Бөек Ватан сугышына багышланган җырлар турында белешмә бирү, Р.Әхмәтҗановның “Солдатлар” һәм татар халык җыры “Герман көе” өйрәнү |
| 9 | Патриот-шагыйрь. Ф.Кәрим иҗаты | Презентация карау,шигырьне тыңлау,сәнгатьле уку,сорауларга җавап бирү,анализ. Бөек Ватан сугышында катнашкан әдипләр турында тарихи мәгълүмат бирү. Ф.Кәримнең тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру, шигырьләре турында фикер йөртә белергә өйрәтү, патриот-шагыйрь булуына басым ясау. |
| 10 | Ф.Кәрим. “Кыңгыраулы яшел гармун” поэмасы | Сәнгатьле уку, өлешләргә бүлү, сорауларга җавап бирү, образларга характеристика. Кыңгыраулы яшел гармун” поэмасының төп фикерен ачыклый белергә өйрәтү. |
| 11 | Исемең калды моңлы бер җыр булып... Т.Миңнуллин иҗаты | Сорауларга җавап эзләү,ишетеп аңлау, рольләргә бүлеп уку,драма әсәре турында фикер алышу.Теоретик төшенчәләр (символик образ,диалог, ремарка)белән эш. Т.Миңнуллин тормыш юлы, иҗаты б-н таныштыру. ”Моңлы бер җыр” драмасын уку һәм нәтиҗә ясау. |
| 12 | Каз канаты каурый,каурый, хатлар язарга ярый. | Хатларның төрләре,аны язу нормалары,аңлатмалы сүзлек б-н эш, хатның эчтәлеген сөйләү,сүзлек өстендә эш. Фронт хатларын уку. Хат язу үзенчәлекләрен өйрәнү |
| 13 | Син күрсәткән батырлыгың солдат... М.Кәрим иҗаты | Шагыйрьнең тормыш юлы белән танышып, хронологик таблица тутыру, шигырьне тыңлау, чылбыр буенча уку, яңа сүзләрне өйрәнү, анализ . Рәсем сәнгате аша Бөек Ватан сугышы турында тарихи мәгълүмат бирү. М.Кәрим тормыш юлы, |

| | | |
|---|---|---|
| 14 | | иҗаты турында белешмә бирү. ”Билгесез солдат” шигырен өйрәнү |
| 14 | Дөньяда бары тик яхшылык кына үлми. Ч.Айтматов иҗаты **Контроль тест№1** | Яңа сүзләрне уку, язу, эчтәлек буенча фикер алышу,сорауларга җавап бирү, әсәрне өлешләргә бүлү, план төзү, өзекне рольләргә бүлеп уку. Ч.Айтматов тормыш юлы, иҗаты турында белешмә бирү. ”Анам кыры” әсәрен өйрәнү. |
| 15 | **Әтинең зур бүреге иртә киелде (3сәг)** Җиңүне якынайткан җыр. К.Булатова иҗаты | Фронталь әңгәмә, шигырьне тыңлап аңлау, сәнгатьле уку, анализ ясау, сорауларга җавап бирү. К.Булатова тормыш юлы, иҗаты б-н танышу. ”Башым иям” шигырен уку. |
| 16 | Тынычлыкның туган көнен бәйрәм итә бүген илем. Н Әхмәдиев иҗаты | Биографияне укып, сорауларга җавап эзләү,шигырьне сәнгатьле уку, яңа сүзләрне өйрәнү, шигырьгә анализ ясау. Н.Әхмәдиев тормыш юлы һәм иҗатын, ”Җиңү көне” шигырен, “Минем туган көнем” хикәясен өйрәнү. |
| 17 | Таң булып нур сибә Ватаным. Р.Вәлиев иҗаты | Презентация карау, шигырьне тыңлау, тәрҗемә итү, сәнгатьле уку, анализ. Р.Вәлиев тормыш юлы иҗаты. “Ватаным” шигырен өйрәнү |
| 18 | **Ана — изге, Ана — бөек, аңа — дан! (6сәг)** Бәхет эзләгәндә. Ш. Камал иҗаты | Сәнгатьле уку, беренче өлешкә план төзү, сорауларга җавап бирү, биремнәрне эшләү, образларга характеристика . Ш. Камал тормыш юлы, иҗаты белән танышу, “Буранда” хикәясен уку. |
| 19 | Тайгак кичүләрне кичкән. И.Салахов иҗаты | Уку,сорауларга җавап бирү, сүзлек б-н эш, автор идеясен билгеләү, биремнәрне эшләү Тарихи вакыйгаларга нигезләнеп, әсәр геройлары яшәгән чорга характеристика бирү. И.Салахов тормышын, иҗаты, “Ана тавышы”өзеген өйрәнү |
| 20 | Ана күңеле – балада. С.Хәким иҗаты | Шигырьне укып, сораулар буенча анализлау, сүзлек б-н эш. С.Хәким тормыш юлы, иҗатын, “Әнкәй” шигырен өйрәнү. |
| 21 | Әнкәйләрдән күргән изгелек. Р.Миңнуллин иҗаты | Сәнгатьле уку, тәрҗемә эше, сорауларга җавап бирү, анализ, нәтиҗә ясый белү, җыр тыңлау. Р.Миңнуллин тормышы, иҗатын, “Әнкәй” шигырен өйрәнү. |
| 22 | Ата-анага бурычны бары тик Кеше булып кына табып | Рольләргә бүлеп уку, Спектакльне карау, сүзлек б-н эш, сорауларга җавап бирү, план төзү, эчтәлек сөйләү, образларга характеристика. Ш.Хөсәенов |

| | | |
|---|---|---|
| | була. Ш.Хөсәенов иҗаты | тормышын, иҗатын өйрәнү, “Әниемнең ак күлмәге” драмасын уку. |
| 23 | Әти-әни кадере. Ф.Садриев иҗаты | Язучы биографиясен һәм иҗатын укып истә калдыру, әсәрне уку. Ф. Садриев тормышы һәм иҗаты белән танышу, “Таң җиле” романыннан өзекләр уку. |
| 24 | **Көлсәң – көл, еласаң – ела! (3сәг)** Көнчелсездән көлке чыкмас. Г.Камал иҗаты | Беренче сатирик журналлар турында әңгәмә, сорауларга җавап, хронологик таблица тутыру, сүзлек б-н эш . Беренче сатирик журналлар турында мәгълүмат бирү, Г.Камалның тормышы һәм иҗатын өйрәнү, “Банкрот” комедиясен уку. |
| 25 | Һәр заманның үз герое була. Г.Афзал иҗаты **контроль тест №2** | Язучы тормышы белән танышу, сүзлек белән эш, укыганны тәрҗемә итү, сораулар, өлешләргә бүлү, план төзү. Г.Афзал тормыш юлы, иҗатын, “Юл газабы” хикәясен өйрәнү. |
| 26 | Табигатьнең дә җаны бар. Озын сүзнең кыскасы. | Сәнгатьле уку, теоретик төшенчәләрне аңлату, сүзлек өстендә эш, фикер алышу, сорауларга җавап бирү. Зәки Нури тормышы, иҗаты белән таныштыру, пародияләр, эпиграммала-рын укып нәтиҗә ясау. |
| 27 | **Даһи гомере – халкы хәтерендә! (2сәг)** Көйләрдән тезмә тездем. Р. Харис иҗаты | Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты белән танышу, хронологик таблица тутыру, поэманы тыңлау, чылбыр буенча уку, яңа сүзләрне өйрәнү. Р.Харис тормыш юлы, иҗаты һәм ”Гармунчы” поэмасын өйрәнү. |
| 28 | Сәхнә хуҗасы. Батулла иҗаты | Язучы иҗатына күзәтү, эчтәлек белән танышу, әсәрнең төп фикерен аңлату, дилогларга бүлеп уку, Р.Нуриев башкаруында бию карау, образга характеристика. Батулланың тормышы һәм иҗаты турында белешмә бирү, “Бию” өзеген уку. |
| 29-30 | **Табигатьнең дә җаны бар (7сәг)** Батыр җайдак. А.Хәлим иҗаты | Язучының тормыш юлы, иҗаты белән танышу, хронологик таблица тутыру, сорауларга җавап бирү, “Өч аяклы ат” фильмын карау. А. Хәлимнең тормышы, иҗаты, “Өч аяклы ат” повестен өйрәнү. |
| 31 | Табигатьнең чәчәк аткан чагы. Гәрәфи Хәсәнов иҗаты | Язучының тормыш юлы, иҗаты белән танышу, хикәяне уку, төп эчтәлекне аңлау, фикер алышу, план төзү . Г.Хәсәнов иҗаты турында белем бирү, “Беренче күк күкрәү” хикәясен уку һәм нәтиҗә ясау. |

| | | |
|---|---|---|
| 32 | Ямьле сабантуйлары. К.Кәрим иҗаты **Еллык контроль тест** | Язучы тормышы белән танышу, фикер алышу, сүзлек белән эш, тәрҗемә, план төзү. К.Кәрим тормыш юлы, иҗаты, “Тимергали бабай хикәяте”н өйрәнү. |
| 33 | “Ялкын” журналына сәяхәт | Бәйләнешле сөйләм үстерү, проект эшен яклап, төркемнәрдә чыгыш ясау. “Ялкын” журналы белән танышу. |
| 34 | Күңелемә уелып калган әсәрләр | Портретлар, төрле иллюстрацияләр, презентацияләр ярдәмендә укылган әсәрләрне кабатлау, тестлар, сорауларга җавап бирү .Ел буена үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау. |
| 35 | Йомгаклау дәресе | Укылган әсәрләрне кабатлау, сорауларга җавап бирү. Укыганны гомумиләштереп нәтиҗә ясый белү. Ел буена үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау. |

## Татар әдәбиятыннан бәяләү нормалары.
## Тыңланган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирүне бәяләү

| № | Таләпләр | Билге |
|---|---|---|
| 1 | Тыңланган текстның эчтәлеген тулаем аңлап, тәкъдим ителгән барлык сорауларга язмача дөрес җавап бирелгән, 1 орфографик хатасы яки эчтәлеккә бәйле 1 хатасы булган эшкә | “5”ле куела. |
| 2 | Тыңланган текстның эчтәлеген аңлап, тәкъдим ителгән сорауларга дөрес җавап бирелгән, әмма 2-3 орфографик, 3 пунктуацион яки эчтәлеккә бәйле 2-3 хатасы булган эшкә | “4”ле куела |
| 3 | Тыңланган текстның эчтәлеген өлешчә аңлап, тәкъдим ителгән сорауларга төгәл җавап бирелмәгән, 5 орфографик, 5 пунктуацион яки эчтәлеккә бәйле 4-5 хатасы булган эшкә | “3”ле кула. |
| 4 | Тыңланган текстның эчтәлеге буенча тәкъдим ителгән сорауларга бирелгән җавапларның яртысы дөрес булмаса, 6 орфографик, 6 пунктуацион яки эчтәлеккә бәйле 5 тән артык хатасы булган эшкә | “2”ле куела |

### Диалогик сөйләмне бәяләү

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора алганда, әйтелеше һәм грамматик төзелеше ягыннан дөрес, эчтәлеге ягыннан эзлекле һәм тулы диалогик сөйләм төзегәндә | “5”ле куела. |

| | | |
|---|---|---|
| 2 | Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора алганда, әмма репликаларның әйтелешендә һәм аерым сүзләрнең грамматик формаларында 2-3 хата җибәреп, эчтәлеге ягыннан эзлекле диалогик сөйләм төзегәндә | “4”ле куела |
| 3 | Өстәмә сораулар ярдәмендә генә әңгәмә кора алганда, репликаларның әйтелешендә һәм сүзләрнең грамматик формаларында 4-6 хата җибәреп, эчтәлеген бозып диалогик сөйләм төзегәндә | “3”ле кула. |
| 4 | Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча диалог төзи алмаганда | “2”ле куела |

## Монологик сөйләм

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча әйтелеше, грамматик төзелеше ягыннан дөрес һәм эчтәлеге ягыннан тулы, эзлекле монологик сөйләм өчен | “5”ле куела. |
| 2 | Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле төзелгән, әмма аерым сүзләрнең әйтелешендә, грамматик формаларында яки җөмлә төзелешендә 2—3 хаталы монологик сөйләм өчен | “4”ле куела |
| 3 | Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле төзелмәгән, сүзләрнең әйтелешендә, җөмлә төзелешендә 4—7 хаталы монологик сөйләм өчен | “3”ле кула. |
| 4 | Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән темага монолог төзи алмаганда | “2”ле куела |

## Шигырьне (яки әсәрдән өзекне) яттан сөйләүне бәяләү

| **Таләпләр** | **билге** |
|---|---|
| Ятларга бирелгән текст әйтелеше дөрес, эчтәлеге ягыннан укучы тарафыннан аңланган, ятланган, сәнгатьле сөйләм өчен | “5” |
| Ятларга бирелгән текст эчтәлеге ягыннан укучы тарафыннан аңланган, ятланган, әмма аерым сүзләрнең әйтелешендә, 2-3 хаталы сөйләм өчен | “4” |
| Ятларга бирелгән текст эчтәлеге ягыннан укучы тарафыннан өлешчә аңланган, ятланган, сүзләрнең әйтелешендә 4-7 хаталы сөйләм өчен | “3” |
| Ятларга бирелгән текст укучы тарафыннан ятланмаган сөйләм өчен | “2” |

**Тест биремнәрен бәяләү**

95-100% - “5”ле
80-94% - “4”ле
51-79% - “3”ле

51% кимрәк булса – “2”ле билгесе куела.

**Йомгаклау билгесе чирек ахырында һәм уку елы беткәндә куела.**

“5” - 4,60-5,0
“4”- 3,60 – 4,50
“3” – 2,60 – 3,50
“2” – 1,60 – 2,0